КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 ноябрь

г.Казань

№ 992

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 15 апрель, 357 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 август, 841 нче, 2022 ел, 10 ноябрь, 1191 нче, 2023 ел, 15 июль, 838 нче, 2024 ел, 28 февраль, 102 нче, 2024 ел, 12 декабрь, 1291 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктны үз көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым категорияләрдәге хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) гражданнарның балаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2023 ел, 7 ноябрь, 1427 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 1 февраль, 53 нче, 2024 ел, 18 июнь, 435 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 6 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2024 ел, 15 февраль, 83 нче карарына, 2 пунктны үз көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» баталь-оннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2024 ел, 18 июнь, 436 нчы карарына, 2 пунктны үз көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә.

5. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин